**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Высокогорский район РТ,
с.Высокая Гора, ул.Центральная, 3

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, ТР Биектау районы,
Биектауавылы, Үзәк ур., 3

Тел./факс: +7(84365) 3-09-88, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

2015 елның 13 марты, № 136

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы " Татарстан Республикасы Биектау авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында фикер алышу буенча ачык тыңлауларны билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32 статьяларына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Биектау авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында.

**КАРАР КЫЛА:**

1. 2015 елның 13 маена «Биектау авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге үзгәрешләр буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Үзәк урамы, 3 нче йорт адресы буенча Биектау авыл җирлеге бинасында «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында <url>/ веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. vysokaya-gora.tatarstan.ru
4. «Биектау авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге үзгәрешләр буенча материаллар күргәзмәләрен, экспозицияләрен оештырырга.
5. «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге үзгәрешләр буенча гавами тыңлауларда җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча белгеч-эшләүчеләрнең катнашуын тәэмин итәргә («Татинвестгражданпроект»ДУП).
6. «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә тәкъдим ителгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, ф.и., авторның туган елы, адреслары күрсәтелгән язма рәвештә комиссиягә җибәрелә дип билгеләргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Биектау авыл җирлеге башлыгы Г. Т. Беспалов